ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 сентябрь 2015 ел № 4948

Башкарма комитетның «Аукционда муниципаль
мөлкәтне сату турында нигезнамәне раслау хакында»
2006 елның 13 ноябрендәге 4341 нче карарының
1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» гы Федераль законга, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турындагы нигезнамәнең 3.18 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет Җитәкчесенең «Аукционда муниципаль мөлкәтне сату турында нигезнамәне раслау турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 4341 нче карарының (Башкарма комитетның 2009 елның 16 сентябрендәге 4003 нче карары, 2010 елның 13 сентябрендәге 5810 нчы, 2014 елның 21 июлендәге 4257 нче, 2015 елның 16 июнендәге 3637 нче карарлары редакциясендә) 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.5. муниципаль мөлкәтне сату буенча аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәр әзерләүне оештыра һәм аны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтына, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан сатулар оештыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендә урнаштыра;»;

2) 2.2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.15. муниципаль мөлкәтне сату буенча аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәр әзерләүне оештыра һәм аны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтына, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан сатулар оештыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендә урнаштыра;»;

3) 4.5.1 пунктындагы «аукцион үткәрү турындагы мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән, аукционда катнашучыларны билгеләү көненнән соң, 10 эш көненнән

дә иртә түгел һәм 15 эш көненнән дә соңга калмыйча» дигән сүзләрне «дәгъвачыларны аукционда катнашучылар дип таныган көннән алып, өченче эш көненнән дә соңга калмыйча» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

3) 4.8.пунктын – үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2015 елның 29 сентябрендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Абдуллин